Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# КАБЕР

Түбән Кама 2010

*Бу китапның асылы ибен Раҗәбнең «Әһүәл әл-кубур үә әхүәлү әһлиһә илә ән-нүшүр» дигән китабыннан алынды*

# Эчтәлек

**Кереш сүз**.......................................................5

Мәетнең кабердәге хәле.........................13

Кабернең мәеткә дәшүе.........................16

Җаннарның яңа мәетнең җаны янында җыелулары.................................................18

Мәетнең изге вә явыз гамәлләре кабердә аңа юлдаш була.......................................19

Кабер әһелләренә иртәсен вә кичен Җәннәттән яки Җәһәннәмнән билгеләнгән урыннары күрсәтелер...................................21

Кабер газабы...........................................22

Бәрзахта мәетләрнең җаннары кайда урнаша?.......................................................26

Шәһидләрнең һәм мөэминнәрнең җаннарын Җәннәткә керүдән тыя торган нәрсәләр...30

Үлгәннәрне зиярат кылып вәгазьләнү хакында.....................................................32

بسم الله الرحمن الرحيم

# Кереш сүз

Үлем ул, ике тормыш – бетүче фәни дөнья тормышы һәм мәңгелек ахирәт[1] тормышы – арасындагы күпер. Дөнья ахирәтнең чәчүлеге. Кем дөньялыгында изгелек эшләсә ахирәттә газабтан котылыр һәм җәннәтләрдә мәңге калыр, ә кем явызлык эшләсә җәһәннәм утында газаб кылыныр, әгәр аны Аллаһ гафу итмәсә.

**Үлем** – ул, бер галәмнән икенче галәмгә күчү, бетү түгел, бәлки ул **рухның тәннән аерылуы**. Һәм рух ул — тәнгә таралган нәфис җисем, яшел үләнгә су таралган кебек. Һәм җан (рух) үлми, бетми. Һәрбер кешегә үлемне искә алу, аңа әзерләнү мөстәхәб[2] булып тора, чөнки пәйгамбәр ﷺ әйтте:

(أَكْثِرُوا مِنْ ذِكْرِ هَاذِمِ اللَّذَّاتِ)

***«Ләззәтләрне кисүче, бетерүче турында күбрәк искә алыгыз (ягъни үлем турында)»[3].***

Үлемгә әзерләнү ул – золым, рәнҗетүләрдән туктау, гөнаһларга тәүбә кылу, тагать-гыйбадәтне арттыру.

Чирле кешенең хәлен белү сөннәт[4] булып тора. Галидән ؓ, пәйгамбәр ﷺ әйтте:

---

1 Ахирәт – үлемнән соңгы тормыш йорты

2 Мөстәхәб – калдыруга караганда эшләү яхшырак булган гамәл. Аны эшләүче саваплы була, ә калдыручы гөнаһлы булмый

3 Тирмизи 2477,2648; Ибен-Мәҗә 4399

4 Сөннәт – пәйгамбәрнең сүзләре яки гамәлләре белән исбатланган, ләкин важиб яки мөстәхәб булмаган эш. Аны эшләүче саваплы була, ә калдыручы шелтәгә лаек

(مَا مِنْ مُسْلِمٍ يَعُودُ مُسْلِمًا غُدْوَةً إِلاَّ صَلَّى عَلَيْهِ سَبْعُونَ أَلْفَ مَلَكٍ حَتَّى يُمْسِيَ وَإِنْ عَادَهُ عَشِيَّةً إِلاَّ صَلَّى عَلَيْهِ سَبْعُونَ أَلْفَ مَلَكٍ حَتَّى يُصْبِحَ وَكَانَ لَهُ خَرِيفٌ فِى الْجَنَّةِ)

***«Бер мөселман икенче мөселманның иртән хәлен белсә, аңа кичкә кадәр 70 мең фәрештә салават[5] кылыр, әгәр кичен хәлен белсә, аңа иртәнгә кадәр 70 мең фәрештә салават кылыр, һәм аңа җәннәттә яңа өлгергән хөрмә җимешләре булыр»[6].***

Чирле кеше янында аңа шифа сорап дога кылу, аның янында «Фәтиха», «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләре кебек кыска сүрәләр уку мөстәхәб. Шулай ук чирлене дәртләндерү мөстәхәб санала, мәсәлән, «син әле яшисең», «син әле терелерсең» кебек сүзләр әйтү. Чирле кеше янында озак утыру, көн уртасында аның янына бару мәкруһ санала. Аның хәлен белү өчен иртән һәм кичен бару мөстәхәб, яхшырак.

Чирле кеше Аллаһ турында яхшы уйда булырга тиеш, аның рәхим-шәфкатенә өметләнергә тиеш, чөнки Ул Аллаһ — иң рәхимле зат, гөнаһларны гафу итүче.

Укылмый калган фарыз намазлары һәм казага[7] калган уразалары өчен һәр намаз һәм һәр көн уразасы өчен бер фитыр садакасы күләмендә фидия[8] бирүне вәсыять[9] әйтеп калдыру тиеш.

Бер кешегә авырлык яки бәла килсә, үлем теләргә тиеш түгел, әгәр инде сабырлыгы җитмәсә, пәйгамбәребез ﷺ өйрәткән шушы доганы кылсын:

(اللَّـهُمَّ أَحْيِنِي مَا كَانَتِ الْحَيَاةُ خَيْرًا لِى ، وَتَوَفَّنِي إِذَا كَانَتِ الْوَفَاةُ خَيْرًا لِى)

5 Монда салават сүзе дога дигән мәгънәдә килә

6 Тирмизи 985; Бәйһакый 6824

7 Каза – гыйбәдәтне билгеләнгән вакыты үткәннән соң үтәү

8 Фидия – җәза буларак, гыйбәдәттә кимчелек кылган өчен, фәкыйрьләргә бирелергә тиешле мал

9 Вәсыять – кешенең башкаларга үзе үлгәннән соң нәрсә дә булса эшләргә әйтеп калдыруы

***«Я Аллаһ, әгәр тереклегем минем өчен хәерлерәк булса, мине терелт, әгәр үлемем минем өчен хәерлерәк булса, мине вафат кыл»[10].***

Әмма Аллаһ юлында шәһид булуны теләү рөхсәт ителә.

Чирле кешене дәваланырга яки ашарга мәҗбүр итү ярамый.

Үлем хәлендәге кешенең тәүбәсе кабул ителә, әмма кәфернең иман китерүе кабул ителми.

Гаргара[11] кылганчы тәлкыйнь[12] әйтелә. **«Лә иләһә илл-Аллаһ Мүхәммәдүр-расүлуллаһ»,** – дип тотып әйтү мөстәхәб.

Хәле авырайган кешегә «Ясин» сүрәсен уку мөстәхәб санала.

Кеше җан бирсә, аның яныннан хәез[13], нифәс[14] һәм җөнеб[15] булган кешеләр чыгарга тиеш.

Үлгән кешенең куллары гәүдәсе буйлап сузып куела, күкрәк өстенә кую ярамый, чөнки алай кәферләр куя. Корсагы өстенә авыррак тимер әйбер куела, эче кабармасын өчен. Киемнәре салдырылып, өстенә җинелчә җәймә каплана.

Юылмаган мәет янында Коръән уку мәкруһ[16] санала.

Мәетне кәфенләнгәнче үбү ярый.

---

10 Бохари 6351; Мөслим 6990; Тирмизи 3110

11 Гаргара – җан биргәндә богаздан чыга торган тавыш

12 Тәлкыйнь – ярдәм итеп әйтеп җибәрү, ягъни иман кәлимәсен исенә төшерү

13 Хәез – хатын-кызның айлык күреме

14 Нифәс – хатын-кызның бала тапканнан соң килә торган күреме

15 Җөнеб – госел алу тиеш булып та, госел алмаган кеше

16 Мәкруһ – занни дәлил белән тыелган эш, хәрамга якын

Бер кешенең мөселман туганы үлсә, шушы доганы уку сөннәт:

(إِنَّـا لِلَّـهِ وَ إِنَّـا إِلَيْهِ رٰجِعُونَ)

***«Иннәә лилләәhи вә иннәә иләйhи раажигуунь»[17].***

«Без Аллаhныкы (ягъни Аллаhның бәндәләре, коллары, безне нишләтсә дә Үз ихтиярында) һәм без Аңа кайтучылар (ягъни безне Үзе теләгән вакытта үтерә, кыямәт көнне кире торгыза һәм Аның алдында җавап тотачакбыз)».

Кеше үлгәч, өч әйберне ашыктыру тиешле: мәетне юып кәфенләү, бурычларын түләү, вәсыятьләрен үтәү.

Кеше үлсә, аның малы иң беренче кәфенләү һәм күмү чыгымнарына тотыла. Аннан соң кешеләргә булган бурычлары түләнергә тиеш. Һәм бу, ягъни аның бурычларын түләү, җеназа[18] намазы укылганчы булырга тиеш, чөнки пәйгамбәр (с.г.в.) әйтте:

(نَفْسُ الْمُؤْمِنِ مُعَلَّقَةٌ بِدَيْنِهِ حَتَّى يُقْضَى عَنْهُ)

***«Мөэминнең җаны бурычына бәйләнгән, хәттә аның өчен түләнгәнчегә кадәр»[19].***

Аннан соң вәсыятьләре үтәлергә тиеш. Вәсыятьләрен үтәү өчен малының өчтән беренә кадәр тотыла. Шуннан артыгын тоту ярамый. Калган малы варисларына бүленә.

Нәфел[20] уразасы тотып, яки нәфел намазы укып, савабын[21] мәеткә багышласа, ягъни Аллаhтан бу гамәлләренең савабын мәеткә ирештерүне сораса,

---

17 Мөслим 2165; Әбү-Давыт 3121

18 Җеназа – мәет; мәет куелган колаша

19 Тирмизи 1099; Ибен-Мәҗә 2506

20 Нәфел - фарыз яки важиб булмаган өстәмә гамәл

21 Савап – түләү, Аллаhның рәхмәтенә ирештерә торган әйбер

мәеткә ирешә. Шулай ук мәет исеменнән садакалар[22] бирсә, хаҗ кылса, Коръән укып яки зекер[23] әйтеп савабын мәеткә багышласа, аңа ирешә.

Сәгъд ибен Губәдәнең ﵁ әнисе үзе өйдә юк чакта вафат булды, ул пәйгамбәр ﷺ янына килде һәм әйтте:

(يَا رَسُولَ اللَّـهِ إِنَّ أُمِّي تُوُفِّيَتْ وَأَنَا غَائِبٌ عَنْهَا فَهَلْ يَنْفَعُهَا إِنْ تَصَدَّقْتُ بِشَيْءٍ عَنْهَا؟ قَالَ: نَعَمْ)

«Әй Аллаһның илчесе! Мин өйдә булмаганда әнием вафат булган. Аның исеменнән садака бирсәм аңа файдасы булырмы?». Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Әйе», –*** диде[24].

Ибен Габбастан ﵁, пәйгамбәр ﷺ әйтте:

(... وَ لاَ يَصُومُ أَحَدٌ عَنْ أَحَدٍ، وَ لَـٰكِنْ يُطْعِمُ عَنْهُ مَكَانَ كُلِّ يَوْمٍ مُدًّا مِنْ حِنْطَةٍ)

***«Бер кеше дә икенче кеше өчен (ягъни мәет өчен) ураза тотмый, ләкин аның исеменнән һәр көн өчен бер мүд[25] бодай бирә (ягъни фитр садакасы күләмендә)»[26].***

Ибен Габбастан ﵁: Җүһәйнә кабиләсеннән бер хатын пәйгамбәр (с.г.в.) янына килде һәм әйтте: «Әнием хаҗ кылырга нәзер итте, ләкин хаҗ кылмыйча үлеп китте, аның өчен хаҗ кылыйммы?». Пәйгамбәр ﷺ әйтте:

(حُجِّي عَنْهَا، أَرَأَيْتِ لَوْ كَانَ عَلَى أُمِّكِ دَيْنٌ أَكُنْتِ قَاضِيَةً اقْضُوا اللَّـهَ، فَاللَّـهُ أَحَقُّ بِالْوَفَاءِ)

---

22 Садака – Аллаһның ризалыгына ирешү өчен бирелә торган әйбер

23 Зекер – Аллаһны искә алу

24 Бохари 2762; Тирмизи 669; Әбү-Давыт 2882

25 Мүд – сагъның дүрттән бере, якынча 400-500 гр

26 Бәйһакый 8492; Тирмизи 722; Мәлик 676

***«Аның өчен хаҗ кыл, әгәр әниеңнең бурычы булса үтәр идеңме, Аллаһка каза кылыгыз (ягъни Аның хакын үтәгез), Аллаһның хакы үтәлергә лаеклырак»[27].***

Ләкин кеше яллап (ягъни түләү биреп) Коръән укыту бидгать[28] булып тора һәм аның савабы мәеткә ирешми. Чөнки Аллаһ тәгалә үз ризалыгы өчен булган ихлас гамәлне генә кабул итә һәм аңа савап була. Ялланып Коръән укучы кеше түләү алырга килешә һәм мондый гамәлгә бернинди савап та булмый. Һәм ул, булмаган савап, ничек мәеткә ирешсен?! Акчага Коръән чыгу шундый савапсыз гамәлләрдән булып тора.

Әгәр берәү каберенә Коръән укучыга фәлән әйбер яки акча бирерсез дип вәсыять әйтеп калдырса, бу вәсыять батыйл[29] була, үтәлергә тиеш түгел.

Әмма түләүсез, үз ризалыгы белән Коръән укып, аның савабын мәеткә багышласа, ул савап мәеткә ирешә, аның өчен хаҗ кылу яки калган уразалары һәм намазлары өчен фидия биргән кебек үк.

Коръән укучы, яки өйрәнүче, яки өйрәтүчеләргә Коръән укыганнары өчен түгел, ә фәкыйрь[30] булганнары өчен ярдәм итү йөзеннән садака бирү рөхсәт ителә.

Җеназа намазына күбрәк кеше килеп өлгерсен өчен генә җеназа намазын укымыйча азрак көтеп тору рөхсәт ителә.

Кешегә үлем якынайса, кыйблага[31] каратып, уң ягына яткырыла, әгәр алай мөмкин булмаса, аякларын кыйбла ягына сузып, баш астына мендәр ке-

27 Бохари 7315; Мөслим 2750

28 Бидгать – дингә шәригатьтә булмаган яңалык кертү

29 Батыйл – бозык, дөрес түгел

30 Фәкыйрь – зәкәт түләрлек нисабы булмаган кеше

31 Кыйбла – Кәгъбәтулла, Мәккә юнәлеше

бек әйбер куела һәм аңа иман кәлимәсе[32] тәлкыйнь ителә. Чөнки пәйгамбәр ﷺ әйтте:

(لَقِّنُوا مَوْتَاكُمْ لاَ إِلَـهَ إِلاَّ الله)

***«Мәетләрегезгә «лә иләһә илл-Аллаһ»ны тәлкыйнь әйтегез»[33].***

Бу хәдистә мәеттән максат — үлеме якынайган кеше. Үлеме якынайган кеше дә мәет дип атала. Аллаһ тәгалә әйтте:

(إِنَّكَ مَيِّتٌ وَ إِنَّهُم مَيِّتُونَ)

**«Син мәет һәм алар да мәетләр».** (әз-Зүмар, 39/30)

Җаны чыкса, күзләре йомдырыла һәм ияге бәйләнеп куела, чөнки шул килеш калдырсаң, кешеләргә ямьсез булып күренә, мәсхәрәләнгән мәет кебек. Аллаһ илчесе ﷺ Әбү Сәләмә янына керде, аның күзләре ачык иде, аларны йомдырды[34].

Кешенең үлүе турында аның туганнарына, дусларына, күршеләренә хәбәр бирүдә зыян юктыр, хәттә алар аңа дога кылсыннар һәм җеназасында катнашып аның хакын үтәсеннәр өчен. Пәйгамбәребез ﷺ Мәдинәнең читендә яшәүче бер мескен хатын турында әйтте:

(إِذَا مَاتَتْ فَآذِنُونِي)

***«Әгәр үлсә, миңа хәбәр бирегез»[35].***

Шулай ук кешенең үлүе турында хәбәр итүдә кешеләрне саваплы эшкә өндәү һәм бер-береңә яхшылыкта ярдәм итешү бардыр. Аллаһ тәгалә әйтте:

(وَ تَعَاوَنُوا عَلَى الْبِرِّ وَ التَّقْوَى)

---

32 Иман кәлимәсе – лә иләһә илл-Аллаһ дигән сүзләр

33 Мөслим 1916; Әбү-Давыт 3117; Тирмизи 976

34 Мөслим 918

35 Нәсәи 1918; Мәлик 537

**«Яхшылыкта һәм тәкъвалыкта[36] бер-берегезгә ярдәм итешегез».** (әл-Мәидә, 2)

Пәйгамбәр ﷺ әйтте:

(الدَّالُّ عَلَى الْخَيْرِ كَفَاعِلِه)

***«Яхшылыкка юл күрсәтүче – аны эшләүче кебек»[37].***

Ләкин базарларда һәм урамнарда кычкырып хәбәр биреп йөрү мәкруһ, чөнки бу җәһилият[38] гадәтләренә охшый.

Мәетне хәзерләүне ашыктыру тиеш. Аллаһ илчесе ﷺ әйтте:

(عَجِّلُوا بِمَوْتَاكُمْ فَإِنْ يَكُ خَيْرًا قَدَّمْتُمُوهُ إِلَيْهِ وَ إِنْ يَكُ شَرًّا فَبُعْدًا لِأَهْلِ النَّارِ)

***«Мәетләрегезне ашыктырыгыз, хәерле булса – хәерлегә якынайтасыз, явыз булса – ут әһелләренә кайгы булсын»[39].***

Рафик хәзрәт Миңлеәхмәт

---

36 Тәкъвалык – Аллаһтан куркып кушканнарын үтәү, тыйганнарыннан тыелу

37 Мөслим 5129; Тирмизи 2671

38 Җәһилият – гарәпләрнең ислам дине килгәнчегә кадәр булган тормышлары

39 Бохари 1315; Мөслим 944; Тирмизи 3015; Әбү-Давыт 3181

## Мәетнең кабердәге хәле

(يُثَبِّتُ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا بِالْقَوْلِ الثَّابِتِ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَفِي الآخِرَةِ
وَيُضِلُّ اللَّهُ الظَّالِمِينَ وَيَفْعَلُ اللَّهُ مَا يَشَاءُ) [ إبراهيم ٢٧ ]

Мәгънәсе: **«Иман китереп хак диндә булган кешеләрне Аллаһ дөньяда вә ахирәттә ныклы сүз белән сабит[40] кылыр, әмма иман китермәгән залимнәрне Аллаһ адаштырыр. Аллаһ теләгән эшне кылыр».**

Бохари[41] һәм Мөслим[42] җыентыкларында әл-Бәраә бин Газибтән ﵁ риваять ителүенчә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: **«Иман китереп хак диндә булган кешеләрне Аллаһ дөньяда вә ахирәттә ныклы сүз белән сабит кылыр...».** ***Бу аять кабер газабы хакында иңдерелде».***

Мөслимдә өстәлде: ***«Мәеткә әйтелер: «Раббың кем?». Мәет әйтер: «Раббым Аллаһ, пәйгамбәрем Мөхәммәд ﷺ». Һәм бу Аллаһның ошбу сүзе:*** **«Иман китереп хак диндә булган кешеләрне Аллаһ дөньяда вә ахирәттә ныклы сүз белән сабит кылыр...».**

Бохари риваятендә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөэмин кабердә утыртылгач, аның янына ике фәрештә килер һәм ул: «Лә иләһә иллә Аллаһ, Мөхәммәд расүл Аллаһ», — дип шәһәдә кәлимәсен әйтер, чөнки Аллаһ тәгалә:*** **«Иман китереп хак диндә булган кешеләрне Аллаһ дөньяда вә ахирәттә ныклы сүз белән сабит кылыр...»,** ***— диде».***

---

40 Ярдәм итәр, булышыр, ныгытыр

41 1369

42 2871

Әт-Табәрани үзенең җыентыгында[43] әл-Бәраә бин Газибтән мондый риваятьне китерде: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кәфердән соралыр: «Раббың кем?», — дип. Ул: «Белмим», — дип җавап бирер. Бу вакытта ул иң саңгырау, иң сукыр һәм иң телсез хәлдә булыр. Шуннан соң аңа зур авыр чүкеч[44] белән сугарлар. Әгәр дә, ул чүкеч белән тауга сугылса, ул тау комга әйләнер иде, һәм бу җәзаны җеннәр белән кешеләрдән башка барчасы да ишетер».*** Шуннан соң расүлебез ошбу аятьне укыды: **«Иман китереп хак диндә булган кешеләрне Аллаһ дөньяда вә ахирәттә ныклы сүз белән сабит кылыр, әмма иман китермәгән залимнәрне Аллаһ адаштырыр. Аллаһ теләгән эшне кылыр».**

Әбү Дауыдта[45] әл-Бәраә бин Газибтән килгән риваятьтә пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, мәет аның яныннан китүчеләрнең аяк киемнәренең тавышларын ишетә. Шул вакытта аннан: «Раббың кем? Динең нинди? Синең пәйгамбәрең кем?», — дип сорала».***

Икенче риваятьтә: ***«Аның янына ике фәрештә килер һәм аны утыртып: «Синең Раббың кем?», — дип сорарлар. Ул: «Раббым Аллаһ», — дип җаваплар. Әйтерләр: «Динең нинди?». Ул: «Минем динем Ислам», — дияр. Аңа әйтерләр: «Сезгә җибәрелгән бу ир-ат кем булыр?». Әйтер: «Ул, Аллаһның илчесе (Мөхәммәд) ﷺ». Алар әйтерләр: «Син моны каян белдең?». Ул: «Мин Аллаһның китабын (Коръәнне) укыдым, аңа иман китердем һәм ышанып расладым», — дип әйтер».***

---

43 «әл-Мүгъҗәм әс-Сагыйрь»

44 Кувалда

45 4753

Җәрир риваятендә болай дип өстәлде: ***«Бу хакта Аллаһ тәгалә болай диде:***

**«Иман китереп хак диндә булган кешеләрне Аллаһ дөньяда вә ахирәттә ныклы сүз белән сабит кылыр...».**

***Шуннан соң күктән нидачы[46] дәшер: «Минем колым хак әйтте. Аңа Җәннәт ятагын түшәгез, Җәннәткә ишек ачыгыз һәм Җәннәт киемнәренә киендерегез!».***

***Аңа Җәннәттән хуш исләр килер һәм кабере күз күреме җиткән кадәр киңәер.***

***Ә кәфер, аның җаны тәненә кайтарылгач янына ике фәрештә килеп, аны утыртырлар һәм: «Раббың кем?», — дип сорарлар. Ул: «Аһ, аһ. Белмим», — дип җавап бирер. Алар аннан: «Динең нинди?», — дип сорарлар. Ул: «Аһ, аһ. Белмим», — дип әйтер. Аннан: «Сезгә җибәрелгән бу ир-ат кем булыр?», — дип сорарлар. Ул: «Аһ, аһ. Белмим», — дип җавап бирер.***

***Шуннан соң, күктән нидачы дәшер: «Колым ялган сөйли. Аңа Җәһәннәм ятагын түшәгез, Җәһәннәм киемнәренә киендерегез, һәм Җәһәннәмгә ишек ачыгыз!».***

***Аңа Җәһәннәмнең кайнар һавасы вә эссесе килеп торыр, һәм кабере шул кадәр нык тараер, хәтта аның кабыргалары бер-берсенә кереп буталырлар».***

Имам Әхмәд риваятендә болай дип өстәлде: ***«Шуннан соң аңа, зур тимер чүкечле сукыр, телсез вә саңгырау беркетелер. Әгәр дә, ул чүкеч белән тауга сукса, комга әйләнер иде. Ул чүкече белән кәфергә сугар, һәм ул комга әйләнер. Шуннан соң, Аллаһ тәгалә аны әүвәлге хәленә кайтарыр. Аңа икенче тапкыр сугарлар һәм ул кешеләрдән вә җеннәрдән***

---

46 Сөрәнче. (Гомумән, нәрсәгә дә булса өндәп, чакырып кычкыру, аваз салу)

***башка, барча мәхлуклар ишетерлек итеп бик каты кычкырыр».***

Мөслимдә Җәбирдән риваять ителде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Һәрбер кеше үлемне ничек каршы алган булса, шул халәтендә кубарылачак».***[47]

Мөэмин кеше иманы белән кубарылыр, монафикъ нифагы белән, ә кәфер көферлеге белән.

Сахих ибен Хиббәндә, ибен Мәҗәһдә[48] Җәбирдән риваять ителде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«(Мөэмин) Мәет кабергә куелгач, аңа кояшның баеганы сүрәтләнер***[49]***, һәм ул күзләрен сөртеп (фәрештәләргә): «Туктап торыгыз, намаз укыймчы!», — дияр».***

## Кабернең мәеткә дәшүе

Тирмизидә[50] Әбү Сәгыйд әл-Худрийдән ؓ риваять ителә: «Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ намаз уку урынына керде һәм анда кешеләрнең елмаешып вә көлешеп торганнарын күреп әйтте: ***«Әгәр дә, сез ләззәтне туктата вә бетерә торган нәрсәне***[51] ***күбрәк искә алсагыз, мин күреп торган гафләт әһелләренең көлү-елмаюларыннан туктар идегез. Ләззәтне кисеп туктата торган үлемне күбрәк искә алыгыз! Чөнки кабернең мәеткә ошбу сүзләр белән дәшмичә***

47 2878

48 4272

49 Ахшам вакытында кояш баеган кебек булыр

50 2460 (шәйх Әлбәний хәдиснең «ләззәтне кисеп туктата торган үлем» җөмләсеннән башка тарафы бик зәгыйфь диде)

51 Үлемне, чөнки ул дөнья белән ләззәтләнүне туктата

***бер генә көне дә үтмәс : «Мин ят йорт[52], мин ялгыз йорт[53], мин балчык һәм корт-суалчан йорты[54]».***

***Әгәр дә, мөэмин кеше күмелсә кабер аңа дәшер: «Рәхим ит! Сиңа монда киңлек һәм изге юлдашлар әзерләнгән. Син минем өчен, өстемдә йөргән иң ягымлы кешеләрдән идең. Ә бүген инде син минем карамагымда калдың, һәм мин сиңа нинди ихсанлык эшләячәгемне күрерсең». Шуннан соң аның кабере күз күреме кадәр ераклыкта киңәер һәм аңа Җәннәткә ишек ачылыр.***

***Ә инде кәфер яки бозык бәндә күмелсә, кабер аңа дәшер: «Сиңа монда киңлек тә изге юлдаш та юк! Син минем өчен, өстемдә йөргән иң нәфрәтле кешеләрдән идең. Ә бүген инде син минем карамагымда калдың, һәм мин синең белән нәрсә эшләячәгемне күрерсең». Шуннан соң аның кабере тараер һәм аны кыса башлар, хәтта аның кабыргалары бер-берсенә кереп буталырлар».***

Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ бармакларын берберсенә аралаштырып ишарәтләп күрсәтте, һәм дәвам итеп әйтте:

***«Һәм Аллаһ тәгалә аңа җитмеш зур елан беркетер, әгәр дә аның берсе генә булса да җиргә агуын чәчсә, анда бернәрсә дә үсмичә дөнья тереклеге бетәр иде, һәм аңа хисап җәзасы җиткәнчегә кадәр ул еланнар аны чагып тешли торган булырлар.***

***Хакыйкатьтә, кабер Җәннәт бакчаларының бер бакчасы, яки Җәһәннәм чокырларының бер чокыры».***

---

52 Миңа керүче, ул - ят кеше

53 Миңа керүче, ул - ялгыз кеше

54 Миңа керүчене балчык һәм корт ашый

## Җаннарның яңа мәетнең җаны янында җыелулары

Нәсәидә[55] Әбү Һурайрадан риваять ителүенчә, пәй-гамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөэминнең үлем вакыты җитсә, аның янына рәхмәт фәрештәләре ап-ак ефәк (кәфенлек) белән килерләр һәм дәшерләр: «Әй җан! Риза вә канәгать булган хәлдә һәм синнән риза булынган хәлдә, Аллаһның рәхмәтенә, сиңа әзерләгән яхшы тормышына тәннән чык!». Аның җаны иң хуш исле хушбуй аңкытып чыгар, һәм ул мәрхүмнең җаны белән фәрештәләр күккә күтәрелерләр. Күк капкасына җиткәч, юлларына очраган фәрештәләр: «Сез җирдән алып килгән бу нинди хуш ис?», — дип сорарлар. Шуннан соң, фәрештәләр мәрхүмнең җанын башка мөэминнәрнең җаннары янына алып килерләр. Ул мөэминнәрнең җаннары бу мәрхүмнең җаны белән очрашкач, сезнең берегез бик озак вакыттан соң танышлары белән күрешкәч ничек шатланыша торган булсалар, ул җаннар аннан да ныграк шатланышырлар. Һәм ул мәрхүмнең җаныннан: «Фәлән кешенең хәле ничек? Ә фәләннеке ничек?», — дип сорарлар. Фәрештәләр аларга әйтерләр: «Ул кешегез хакында сорашмагыз, чөнки ул дөнья белән алданган иде». Мәрхүмнең җаны мөэминнәрнең җаннарыннан: «Ул кеше җаны сезнең янга килмәдемни?», — дип сорагач, алар аңа: «Аны инде алайса Җәһәннәмгә алып киткәннәр», — дип әйтерләр...».***

55 1833 (сахих)

## Мәетнең изге вә явыз гамәлләре кабердә аңа юлдаш була

Әт-Табәрани үзенең җыентыгында[56] Әбү Һүрайрадан ﵁ ошбу риваятьне китерде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ белән ант итәм! Хакыйкатьтә, сез мәет яныннан киткәндә, ул сезнең аяк киемнәрегезнең тавышларын ишетә. Әгәр дә мәет мөэмин булса, аның намазы баш очында урнашыр, зәкәте уң тарафында урнашыр, уразасы сул ягында урнашыр, ә инде изгелекләре вә кешеләргә күркәмлеге аягы тарафында урнашыр. Шуннан соң, аның янына (җәза белән) башы тарафыннан килерләр, намазы әйтер: «Сезгә минем ягымнан юл юк», — дип. Аннары уң ягыннан килерләр, зәкәте әйтер: «Сезгә минем тарафымнан да юл юк», — дип. Сул ягыннан килерләр, уразасы әйтер: «Сезгә минем тарафымнан юл юк», — дип. Алай да булмагач аягы ягыннан килерләр, изгелекләре вә кешеләргә күркәмлеге әйтер: «Сезгә минем тарафымнан да юл юк», — дип. Шуннан соң мәеткә әйтелер: «Утыр!», — дип, һәм ул утырыр. Кояш баеган кебек тасвирланыр, һәм аннан: «Сезгә җибәрелгән бу ир-ат[57] хакында нәрсә әйтә аласың?», — дип сорарлар. Ул: «Мин шәһидлек кылам, ул Аллаһның илчесе. Раббыбыз тарафыннан хаклык белән килде, без аңа ышандык һәм иярдек», — дип җавап бирер. Аңа әйтерләр: «Син дөрес әйттең, һәм шуның[58] белән яшәдең вә үлдең, һәм Кыямәт көнендә дә шуның белән кубарылачаксың, иншәАллаһ». Шуннан соң аның кабере күз күреме еракльігында киңәер, һәм***

56 «әл-Мүгъҗәм әл-Әүсәтъ»

57 Ягъни, Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ

58 Иман

***бу Аллаһ тәгаләнең Коръәндәге ошбу аятенә муафыйк: «Иман китереп хак диндә булган кешеләрне Аллаһ дөньяда вә ахирәттә ныклы сүз белән сабит кылыр...». Әйтерләр: «Бу мәеткә Җәһәннәмгә ишекне ачыгыз!». Һәм аңа мөрәҗәгать итеп: «Әгәр дә Аллаһка итагать итмәгән булсаң, бу синең урының булыр иде», — дип әйтерләр. Болардан соң мәрхүмнең шатлыгы вә сөенче артыр. Шуннан соң әйтерләр: «Бу мәеткә Җәннәткә ишекне ачыгыз!», — дип, һәм ишек ачылыр, шуннан соң аңа: «Бу, Аллаһ сиңа әзерләгән урының», — диерләр. Болардан аның шатлыгы вә сөенече тагын да ныграк артыр...».***

Имам Әхмәдтә әл-Бәраә бин Газибтән ﷺ килгән риваятьтә болай дип өстәлде: ***«Мөэмин мәет янына күркәм йөзле, күркәм киемле вә хуш ис аңкып торган бер кеше килер һәм аңа: «Сине куандыра торган нәрсәгә шатлан! Бу сиңа әүвәл вәгъдә ителгән көн!». Мәрхүм аңа: «Син кем? Синең йөзең яхшылык китерүчегә охшаган». Тегесе аңа: «Мин синең изге гамәлең», — диер. Шуннан соң мәрхүм: «Йә Раббым! Үземнең әһелләрем белән булырга тизрәк Кыямәт көнен якынайт!», — дип әйтер».***

Кәфер хакында болай диде: ***«Аның янына кабахәт-куркыныч йөзле, кабахәт киемле вә бик сасы исле кеше килер, һәм кәфергә: «Сине хәсрәтләндерә торган нәрсәгә кайгыр! Бу синең вәгъдә ителгән көнең», — диер. Кәфер аннан: «Син кем? Синең йөзең явызлык белән килүчегә охшаган», — дип сорар. Тегесе аңа: «Мин синең кылган явызлыгың», — дип әйтер. Шуннан соң ул кәфер: «Йә Раббы! Кыямәтне булдырма», — дип ялварыр».***

Шулай ук, боларның барсын да Бохарида[59] һәм Мөслимдә[60] Әнәс бин Мәликтән риваять ителгән хәдис исбатлый. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Өчәү мәетне озатып баралар: Аның гаилә әһелләре, аның малы  һәм аның эшләре. Ләкин икесе кире кайтып китә, һәм берсе генә аның белән кала. Аның гаилә әһелләре һәм аның малы кире кайтып китә, ә аның гамәлләре үзе белән кала».***

## Кабер әһелләренә иртәсен вә кичен Җәннәттән яки Җәһәннәмнән билгеләнгән урыннары күрсәтелер

(النَّارُ يُعْرَضُونَ عَلَيْهَا غُدُوًّا وَعَشِيًّا وَيَوْمَ تَقُومُ السَّاعَةُ أَدْخِلُوا آلَ فِرْعَوْنَ أَشَدَّ الْعَذَابِ) [ غافر: ٤٦ ]

Мәгънәсе: **«Аларга иртә дә, кич тә ут газабы күр-сәтелер, әмма Кыямәт көне булгач Фиргавен кавемен газабның катысына кертегез, диелер».**

Бохарида[61] һәм Мөслимдә Габдуллаһ бин Гомәрдән ؓ риваять ителде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, сезнең һәрберегезгә үлгәннән соң иртәсен һәм кичен тиешле урыннарын күрсәтәчәкләр. Әгәр дә мәет Җәннәт әһелләреннән булса, аңа Җәннәт әһелләре арасындагы урынын күрсәтерләр. Әгәр мәет Җәһәннәм әһелләреннән булса, аңа Җәһәннәм әһелләре арасындагы урынын күрсәтерләр. Һәм аңа әйтерләр: «Кыямәт көнендә Аллаһ сине кубарганчыга кадәр, бу синең урының булачак!», — дип».***

---

59 6514
60 2960
61 1379

## Кабер газабы

Кабер газабы Коръәндә һәм хәдисләрдә искә алынды. Мәсәлән, «әл-Әнгам» сүрәсенең 93нче аятендә Аллаһ тәгалә болай диде: **«Әгәр син залимнәрнең үлгән вакытларын күрсәң, бик авыр хәлдә, каты газаб астында булырлар. Фәрештәләр аларга сугар өчен кулларын сузып: «Җаннарыгызны чыгарыгыз. Аллаһка тиешсез сүзләр әйткәнегез һәм Аның аятьләре белән гамәл кылудан тәкәбберләнгәнегез өчен, бүген хур итүче газаб белән җәза ителәсез, – диерләр».**

Тирмизидә[62] Галидән ﵁ риваять ителгән әсәрдә болай диелде: ***«Дөнья малын күбәйтү белән мактанышуларыгыз, үлеп кабергә кергәнегезгә хәтле сезне гафил кылды»[63] дигән аять иңгәнчегә кадәр без кабер газабында шикләнә идек, ул аять иңгәч шигебез бетте».***

Сахих ибен Хиббәндә Әбү Һүрайрадан ﵁ риваять ителде, пәйгамбәребез ﷺ **«Хакыйкатьтә, аңа тар тормыш булыр»[64]** – дигән аять хакында: ***«Ул кабер газабы»,*** – диде».

Ибен Хиббәндә Әбү Һүрайрадан ﵁ килгән икенче риваятьтә пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөэмин кеше каберендә яшеллек бакчасындагы кебек булыр. Аның кабере җитмеш терсәк озынлыгында киңәер һәм тулган ай яктырткан кебек нурлы вә якты булыр.*** **«Хакыйкатьтә, аңа тар тормыш булыр, һәм Без аны Кыямәт көнендә сукыр итеп кубарырбыз»[65].** ***Сез ошбу аять ни сәбәпле***

---

62 3355 (шәйх Әлбәни иснәде зәгыйфь диде)

63 Әт-Тәкәсүр 1-2

64 Таһә 124

65 Таһә 124

***иңдерелгәнен һәм* «Тар тормыш» *нәрсә икәнен беләсезме?», — диде.*** Сахәбәләр: «Аллаһ һәм Аның расүле яхшырак беләләр», – дип җавап бирделәр. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ул кәфернең кабердәге газабы. Аллаһ белән ант итәм, хакыйкатьтә, аны туксан тугыз зур елан әсир итәр. Сез беләсезме бер зур еланны? Ул җиде башлы җитмеш елан. Кәферне Кыямәткә кадәр тешли вә чага торган булыр».***

Ибен Габбастан ؓ **«Аларга олуг газаптан әүвәл, әлбәттә, кечкенә газапны татытачакбыз»[66]**, – дигән аять хакында: ***«Ул, кабер газабы»,*** – дип риваять кылынды.

Катәдә һәм Рабигъ бин Әнәс **«Без аларны ике тапкыр газаплярбыз»[67]**, – дигән аять хакында: ***«Берсе дөньяда икенчесе кабер газабы»,*** – диделәр.

Бохарида[68] һәм Мөслимдә[69] килгән хәдистә, Гаишә пәйгамбәребездән ﷺ кабер газабы хакында сорагач, расүлебез ﷺ : ***«Әйе, кабер газабы - хак»,*** – диде. Гаишә әйтте: ***«Һәм шуннан соң, мин пәйгамбәребезнең ﷺ кайсы намазын гына укыса да, ахырдан кабер газабыннан сыгынып дога кылганын күрә идем».***

**Кабердә газаплануның кайбер сәбәпләре:**

Бохарида[70] һәм Мөслимдә[71] Ибен Габбастан ؓ риваять кылынуынча, пәйгамбәребез ﷺ ике кабер яныннан узып барганда әйтте: ***«Дөреслектә, аларны газаплыйлар һәм зур гөнаһ өчен түгел: Берсе***

---

66 Әс-сәждә 21
67 Әт-тәүбә 101
68 1372
69 586
70 216, 218, 1361, 1378, 6052, 6055
71 492

***үз бәвеленнән[72] пакьланмый торган булган, икенчесе нәмимә[73] йөрткән»[74].***

Ибен Мәҗәһдә[75] Әбү Һүрайрадан ﷺ риваять кылынуынча, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кабер газабының иң күпчелеге бәвелдән булачак».***

Кайбер гыйлем әһелләре бәвел, гайбәт һәм нәмимәнең кабер газабы белән тәгаенләнүвенең серен болай дип аңлатып уздылар:

«Кабер ул ахирәтнең иң әүвәлге йорты, һәм анда Кыямәт көнендә буласы җәза белән саваптан беренче мисаллар билгеләнгән.

Кыямәт көнендә җәзаланасы гөнаһлар ике төрле: Беренчесе Аллаһ тәгаләнең хакы белән бәйле гөнаһлар, икенчесе бәндәләр хакы белән бәйле гөнаһлар. Һәм Кыямәт көнендә Аллаһ тәгаләнең хакы белән бәйле гөнаһлардан иң беренче булып кеше – намазы өчен хисап тотар, ә инде бәндәләр хакы белән бәйле гөнаһлардан иң беренче булып – хаксызга кан түгү өчен хисап тотар.

Шуңа да, кабердә намаз белән кан хакы хисабына бәйле, аларның башлангыч сәбәпләре өчен кеше хисап тотар. Намазның башы – нәҗесләрдән пакьлану, кан хакының башы – гайбәт, нәмимә һәм кешеләр намусын пычрату. Шуңа да, иң беренчеләрдән мәет кабердә шушы ике нәрсә өчен җәза кылына башлый, һәм болар аның өчен иң җиңел изалар[76] була».

---

72 Сидек

73 Кешеләр арасын бозу нияте белән ялган сөйләп сүз йөртүче

74 Пәйгамбәребезнең бу сүзләре хакында гыйлем ияләре төрле фикерләрне әйттеләр, ләкин аларның барсы да: «Бу кабердәгеләр икесе дә үзләренең гөнаһларына бернинди дә әһәмият бирмәгән, ләкин ул гөнаһлар Аллаһ каршында бик тә җитди булып санала», — дигән мәгънәгә килделәр.

75 348 (сахих)

76 Газап, җәфа, интегү

Шулай итеп, ошбу вә башка хәдисләрдән билгеле булганча таһәрат, намаз, ураза, зәкәт, изгелеккә боеру вә начарлыклардан тыю, һәр кичтә «әл-Мүлк» сүрәсен уку[77], җомга төнендә яки көнендә вафат булу[78] мөэмин кешене кабер газабыннан саклый.

Ә инде Аллаһ юлында җиһәд кылучы хакында пәйгамбәребез ﷺ болай диде: ***«Шәһидне Аллаһ хозурында алты табыш көтә: Иң беренче тамчы каны таму белән барча гөнаһлары да ярлыкана; Җәннәттәге урыны күрсәтелә; Кабер газабыннан котыла; Кыямәт көнендә имин була; Башына таҗ кидерелә, ул таҗның якуты бу дөньядан һәм дөньяда булган барча нәрсәдән дә хәерлерәк; Җитмеш ике хур кызына өйләндерелә һәм җитмеш туганына шәфәгать кыла»[79].***

Нәсәидә[80] килгән икенче риваятьтә, берәү пәйгамбәребез ﷺ янына килеп: ***«Әй Аллаһның илчесе! Мөэминнәр барчасы да каберләрендә фетнәләнерләр, ләкин шәһид фетнәләнмәс, бу ни өчен болай?»,*** – дип сорагач, пәйгамбәребез аңа: ***«Мөҗәһиднең баш өстендә кылыч уйнавы аңа фетнә өчен җитә»,*** – дип җавап бирде.

## Кабер газабының төрләре:

Кабер газабының кайбер төрләре хакында болай дип бәян ителде:

**1)** Зур чүкеч яки шуңа охшаш нәрсәләр белән кыйналу.

**2)** Еланнар һәм чаяннар әсирлегендә булыр.

---

77 Сахих әт-тәргыйб вә әт-тәрһиб 1589 (шәйх Әлбәни)

78 Тирмизи 1074 (хәсән)

79 Тирмизи 1663 (сахих)

80 2053 (сахих)

**3)** Мәетнең башын, авызларын таш белән сугып газаплардар һәм башкалар[81].

**4)** Кабернең тараюы, хәтта мәетнең кабыргалары бер-берсенә кереп китә.

## Бәрзахта[82] мәетләрнең җаннары кайда урнаша?

**❁ Пәйгамбәрләрнең җаннары:**

Пәйгамбәрләрнең җаннары Аллаһ хозурында иң югары дәрәҗәләрдә. Чөнки пәйгамбәребез ﷺ вафат булыр алдыннан: ***«Әй Аллаһ, мине гафу ит, мине ярлыка һәм иң югары җәмәгатькә кушылдыр!»,*** – дип дога кыла иде[83].

Сәгыйд бин Зәйд ибен Мәсгудтан: ***«Пәйгамбәребез ﷺ вафат булды, ул хәзер кайда?»,*** – дип сорагач, ибен Мәсгуд аңа: ***«Җәннәттә»,*** – диде[84].

**❁ Шәһидләрнең җаннары:**

Күпчелек гыйлем әһелләре шәһидләрнең җаннары Җәннәттә, һәм бу хакта бик күп хәдисләр риваять ителде диделәр.

Сахих Мөслимдә[85] Мәсруктан риваять ителә: «Без Габдуллаһ бин Мәсгудтан ошбу аять хакында сорадык: **«Аллаһ юлында үлгәннәрне, мәетләр дип һич тә уйламагыз! Бәлки алар тереләр һәм Раббылары хозурында ризыкланалар»[86].** Ул әйтте: Без бу

81 Бохари 1386

82 Үлгәннән алып Кыяматкә кадәр, дөнья белән ахирәтне аерып торучы бер урын. Кем үлде икән, шунда керә

83 Бохари 5674

84 Әт-Табәрани «әл-Мүгъҗам әл-Кәбир»

85 1887

86 Әли-Гыймран 169

хакта пәйгамбәребездән сораган идек, һәм ул болай диде: ***«Аларның җаннары яшел кошларның карынында, һәм алар өчен гарешкә кәндилләр[87] эленгән. Җәннәтнең теләгән урынында йөриләр вә шул кәндилләргә килеп сыеналар. Раббылары алардан: «Сез берәрнәрсә телисезме?», — дип сорар. Алар: «Без Җәннәттә үзебез теләгән җирдә йөрибез, тагын нәрсә тели алабыз инде?!», — диярләр. Раббылары алар белән шулай өч тапкыр эшләр, һәм алар бу сораудан болай гына калмаячакларын белгәч, Рабыларына: «Әй Раббы! Синең юлыңда тагын үлер өчен, безнең җаннарыбызны тәннәребезгә кайтарчы!», — дип сорарлар. Шуннан соң, Аллаһ тәгалә аларның бернинди хаҗәтләре дә юклыгын күргәч, аларны калдырыр».***

Шулай ук, шәһидләрнең җаннары Җәннәттә булуы хакында Бохарида[88] һәм Мөслимдә[89] килгән ошбу риваять ишарәт итә, Җәбир ﵁ әйтте: «Үхүд сугышы көнендә бер кеше пәйгамбәребездән ﷺ: «Әйт әле миңа, әгәр мине үтерсәләр, мин кайда булырмын?», – дип сорады. Ул: ***«Җәннәттә»,*** – диде, һәм шунда бу кеше кулындагы хөрмәләрне ташлады да, вә сугышка кереп шәһид булып үлгәнче сугышты».

**Шәһидләрдән башка мөэминнәрнең җаннары:**

Шәһидләрдән башка мөэминнәрнең җаннары икегә бүленә: тәклиф әһелләренекенә[90] һәм тәклиф әһелләреннән булмаучыларныкына[91].

---

87 Берничә шәм куела яки электр лампочкалары беркетелә торган шәмдәл
88 4046
89 1899
90 Шәригатне үтәү белән йөкләнгәннәр
91 Шәригатне үтәү белән йөкләнмәгәннәр (сабыйлар вә мәҗнүннәр кебек)

**Беренче: *Мөэминнәрнең сабый балалары кебек тәклиф әһелләреннән булмаучылар:***

Гыйлем әһелләренең җөмһүре, аларның җаннары Җәннәттә диде. Бу хакта имам Әхмәдтән риваять кылынды.

Җәгьфар бин Мөхәммәд риваятендә: «Аларның Җәннәттә булуларында бер төрле капма-каршылык та юк», – диелде.

Әл-Мәймүни риваятендә: «Аларның Җәннәттә булуларында беркем дә шикләнми», – диелде.

Ибен Хиббән «Сахихында» һәм әл-Хәким «Мүстәдрәктә» Әбү Һүрайрадан ﷺ ошбу риваятьне китерделәр. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөэминнәрнең сабыйлары Җәннәттә Ибраһим ﷺ карамагында булырлар».***

Икенче риваятьтә пәйгамбәребез ﷺ: ***«Мөселманнарның балалары Җәннәттә Ибраһим ﷺ һәм Сәра карамагында булырлар, ә инде Кыямәт көне җитсә ата-аналарына кайтарылырлар»,*** – диде.

Бу риваятьләргә шулай ук, Бохарида[92] Сәмүра бин Җүндүбтән килгән хәдис ишәрат кыла. Пәйгамбәребез ﷺ төшендә Җибраил белән Микәил аның янына килеп, үзләре белән алып киткәннәрен күрде, һәм бик озын хәдисне искә алып узды. Бу хәдиснең бер өлешендә болай диелде: ***«Без тагын кузгалдык, һәм зур агач үскән яшел бакчага кадәр бардык. Ул агач астында сабый-балалар белән бер карт утыра иде. Шулай ук, агач янәшәсендә янган учакны искә алып торган тагын бер кеше тора иде. Шуннан соң юлдашларым мине шушы агачка алып менделәр һәм бик матур йортка алып керделәр. Мондый матур йортны минем беркайчан да күргәнем***

92 1386

***юк иде, вә аның эчендә картлар, яшьләр, хатын-кызлар һәм сабыйлар бар иде. Шуннан соң алар мине аннан алып чыктылар, һәм агачның тагын да өстенәрәк алып менделәр вә картлар һәм яшьләр булган икенче, тагын да матуррак, күркәмрәк йортка алып керделәр».***

Хәдис дәвам иткелде һәм азагында: ***«(Җибраил белән Микәил) әйттеләр: «Агач астында утырган карт — Ибраһим ﷺ, ә аның янәшәсендәге сабый-балалар — кешеләрнең балалары».*** Башка риваятьтә: ***«Фитрәт хәләтендә үлгән балалар»,*** – диелде. ***«Беренче кергән йортың — барча мөэминнәрнең дә йорты, әмма бу (икенче) йорт — шәһидләрнең йорты».***

**Икенче:** ***Шәһидләрдән башка тәклиф әһелләреннән булган мөэминнәр:***

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре элек тә, хәзер дә төрле карашларга бүленделәр. Имам Әхмәдтән билгеле булганы, мөэминнәрнең җаннары Җәннәттә. Моны әл-Халләл «Әс-Сүннәһ» китабында Хәнбәлдән искә алып узды. Әйтте: Мин Әбү Габдуллаһның болай дип әйткәнен ишеттем: «Мөэминнәрнең җаннары Җәннәттә». Икенче урында Хәнбәл болай диде: «Мөэминнәрнең җаннары Җәннәттә, ә кәферләрнеке Җәһәннәмдә».

Габдуллаһ бин Гамрдан болай дип риваять кылынды: «Мөэминнәрнең җаннары сыерчык шикелле яшел кош эчендә, алар шунда (Җәннәттә) берберсе белән күрешәләр һәм андагы җимешләрдән ризыкланалар»[93].

---

93 Мусаннаф Ибен Әбий Шәйбәһ

Мөэминнәрнең җаннары Җәннәттә, әкәферләрнеке Җәһәннәмдә дигән карашка Коръәннән ошбу аятьләрне китерергә мөмкин:

(قِيلَ ادْخُلِ الْجَنَّةَ قَالَ يَا لَيْتَ قَوْمِي يَعْلَمُونَ ۞ بِمَا غَفَرَ لِي
رَبِّي وَجَعَلَنِي مِنَ الْمُكْرَمِينَ) [ يس: ٢٦-٢٧ ]

Мәгънәсе: **«Бу мөселманга үлгәннән соң: «Җәннәткә кер», – диелде. Һәм ул әйтте: «Кавемем минем хәлемне, Раббым мине ярлыкаганын һәм Үзе хозурында хөрмәтлеләрдән кылганын белсәләрче?!».**

Ул, бу сүзләрне үтерелгәннән соң, һәм аңа Аллаһ нәрсә әзерләгәнен күргәннән соң әйтте.

Шулай ук, әл-Бәззәрда Җәбирдән ﵁ риваять ителде, пәйгамбәребездән ﷺ Хәдиҗә хакында соралгач, ул: ***«Мин аны Җәннәт елгаларының берсендә, эче куыш энҗедән ясалган йортта күрдем, һәм анда тавыш та, ару да булмас»[94]***, – диде.

## Шәһидләрнең һәм мөэминнәрнең җаннарын Җәннәткә керүдән тыя торган нәрсәләр

Шәһидләрнең һәм мөэминнәрнең җаннарын Җәннәткә керүдән тыя торган җәза яки әдамнәрең хокукларын үтәү кебек бурычлары булмаса, алар Җәннәткә керә. Әгәр дә тыя торган нәрсәләр булса, шулардан пакьланганчыга кадәр тыелып торалар.

94 Бу хәдискә Бохари җыентыгында (3819, 3820) ишарәт бар

Бохари[95] һәм Мөслимдә[96] Әбү Һурайрадан ﷺ риваять итеЛә: Мидгам Хайбәр көнендә үтерелгәч, кешеләр аны пәйгамбәребезгә ﷺ хезмәт итеп шәһид булып үлде дип белделәр, һәм: «Җәннәттә рәхәтләнсен», - диделәр. Пәйгамбәребез ﷺ аларга: ***«Юк! Аллаһ белән ант итәм. Хакыйкатьтә, ул Хайбәр көнендә бүленмәгән табыштан алган япма[97], ут белән ялкынлана!»,*** – диде.

Сәмүра бин Җүндүбтән ﷺ риваять итеЛә: Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ безнең белән намаз укыганнан соң: ***«Бәнү фүләннән берәр кеше бармы?»,*** - дип өч тапкыр сорады. Беркем дә җавап бирмәде. Бераз вакыттан соң бер ир-ат бу сорауга дәште, һәм пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Хакыйкатьтә, вафат булган фәлән кеше өстендәге бурычы сәбәпле Җәннәттән тоткарланды. Аның бурычын түләп аны азат итегез, яки инде теләсәгез, Аллаһ тәгаләнең газабына тапшырыгыз!»,*** – диде[98].

Тирмизидә[99] һәм ибен Мәҗәһдә[100] Сәүбәннән ﷺ риваять ителде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кешенең җаны тәненнән аерылса һәм ул ошбу өч нәрсәдән: тәкәбберлектән, ганимәт малында хыянәттән һәм бурычтан пакь булса — Җәннәткә керде».***

---

95 4234, 6707

96 115

97 Җиңсез кием (урысчадагы плащ, накидка кебек)

98 Шушы мәгънәдәге хәдис Әбү Дауыдта (3341), Әхмәд бин Хәнбәлнең “Мүснәдендә” килде

99 1572, 1573

100 2412

## Үлгәннәрне зиярат кылып вәгазьләнү хакында

Мөслимдә[101] Бүрайдәдән ﵁ риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мин сезне каберләргә зиярат кылудан тыйган идем, ә хәзер инде зиярат итегез...».***

Имам Әхмәдтә болай диелде: ***«Каберләрне зиярат итегез! Хакыйкатьтә, аларны зиярат итүдә гыйбрәт һәм вәгазь!».***

Әбү Сәгыйд әл-Худрийдән ﵁ мондый риваять китерелде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Каберләрне зиярат итегез! Хакыйкатьтә, аларны зиярат итү күңелнең дөньяга ашкынуын сүндерә һәм ахирәтне искә төшерә».***

Шулай ук, имам Әхмәдтә Әнәстән ﵁ риваять ителде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мин сезне каберләрне зиярат итүдән тыйган идем, ә инде хәзер зиярат итегез! Чөнки ул йөрәкне йомшарта, күзләрне яшьләндерә һәм ахирәтне искә төшерә. Ләкин, (аларны зиярат иткәндә һәм мәетләрне искә алганда) беркайчан да начар сүз сөйләмәгез!».***

Мөслимдә[102] Әбү Һүрайрадан ﵁ риваять ителде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Раббымнан әниемнең каберен зиярат итәргә рөхсәт сорадым, һәм Ул рөхсәт итте. Каберләрне зиярат итегез! Чөнки ул үлемне искә төшерә».***

Әбү әд-Дүнья Сәләм бин Салихтан ошбу риваятьне китерә: «Кәннәрнең берендә әл-Хәсән әл-Бәсърий юкка чыкты, һәм кич белән күренгәч аннан иптәшләре: «Син кайда булдың?», – дип сорадылар.

101 977
102 976

Ул: «Мин бүген үземнең кардәшләрем янында булдым. Әгәр дә мин онытсам, алар исемә төшерәләр, ә инде алар янында булмый торсам, мине гаепләмиләр вә битәрләмиләр», - диде. Иптәшләре аңа: «Әй Әбү Сәгыйд! Аллаһ белән ант итәбез! Алар искиткеч кардәшләр, безгә дә аларны күрсәтче?», - диделәр. Әл-Хәсән әл-Бәсърий аларга: «Алар кабер әһелләре», - диде».

Тирмизидә[103] һәм ибен Мәҗәһдә[104] Һәниәдән риваять ителә: «Әгәр дә Госман ﵁ кабер янына басса, елый торган иде. Хәтта, күз яшьләреннән аның сакалы юешләнеп чыга иде. Аңа: «Җәннәтне һәм Җәһәннәмне искә төшергәч еламыйсың, ә каберне искә төшергәч елыйсың?», – диделәр. Ул әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Кабер ахирәтнең беренче йорты, әгәр дә аннан котылсаң[105], кабердән соң килгәне җиңелрәк булыр, ә инде котыла алмасаң, аннан соң килгәне тагын да катырак вә куркынычрак булыр. Мин кабердән дә куркынчрак күренеш күрмәдем!»,*** – диде».

Ибен Мәҗәһдә[106] һәм имам Әхмәдтә[107] әл-Бәраә бин Газибтән ﵁ риваять ителә: «Көннәрнең берендә без пәйгамбәребез ﷺ белән җеназада булдык, ул кабер читенә утырды да елап җибәрде, хәтта аның күз яшеннән туфрак юешләнде, шуннан соң ул: ***«Әй кардәшләрем! Шушындый көнгә изге гамәлләр әзерләгез!»,*** – диде».

---

103 2308 (шәйх Әлбәний хәсән диде)
104 4267
105 Ягъни, кабер газабыннан
106 4195 (шәйх Әлбәний хәсән диде)
107 Мүснәдендә

Имам Әхмәдтә[108], Тирмизидә[109] һәм әл-Хәкимдә[110] Габдуллаһ бин Мәсгудтән ﷺ риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгаләдән хак оялу белән оялыгыз!»[111].*** Без аңа: «Әй Аллаһның илчесе! Без бит оялабыз, әлхәмдүлилләһ!», – дидек. Ул: ***«Сез уйлаганча түгел! Ләкин Аллаһтан хак оялу белән оялу, ул: башны һәм андагы әгъзаларны саклау[112], эчне һәм аның белән бәйле нәрсәләрне саклау[113], үлемне һәм кабердә үзеңнең череп бетүеңне искә төшерү һәм ахирәткә омтылган кешенең дөнья зиннәтен ташлавы[114]. Кем дә кем ошбу нәрсәләрне булдырса, ул кеше Аллаһтан хак оялу белән оялган була!»,*** – диде».

Тирмизидә[115] һәм әл-Хәкимдә[116] Әсмә бинт Гумәйстән риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Бөеклек вә өстенлек фәкать Аллаһка гына тиешле дигәнне онытып, үзен башкалардан өстен дип уйлаган һәм тәкәбберләнгән бәндә – иң хәсрәтле бәндә. Барча нәрсәгә көче җитүче бөек Аллаһны онытып,***

---

108 Мүснәдендә

109 2458 (әл-Хәким һәм әз-Зәһәбий сахих диделәр, шәйх Әлбәний хәсән диде)

110 Мүстәдрактә

111 Кайберәүләр: "Аллаһка хак тәкъвалык белән тәкъваланыгыз!", - дип аңлатты

112 Башны Аллаһ тәгаләдән башкага итагать итүдән саклау, ягъни, Аннан башкага сәҗдә кылмаска, рия кылып намазлар укымаска, Аңа гына түбәнчелек күрсәтергә, тәкәбберлек белән башны күтәрмәскә, телне, күзләрне, колакларны хәрамнарга кулланмаска һ.б.

113 Карынны хәрамнардан саклау, һәм аның белән бәйле җенес әгъзаны, аякларны, кулларны, йөрәкне гөнаһлы эшләрдән саклап иллә-мәгәр Аллаһка итагатьтә генә куллану

114 Бу ике нәрсә (дөнья белән ахирәт) беркайчан да камил рәвештә бергә була алмыйлар. Чөнки, алар көндәшләр, әгәр дә берсен канәгатьләндерсәң, икенчесен һичшиксез ачуландырасың

115 2448 (Тирмизи, әл-Мүнәүи һәм шәйх Әлбәний зәгыйфь диделәр)

116 Мүстәдрактә

***башкаларны җәберләгән вә золым кылган бәндә – иң хәсрәтле бәндә. Хаклыктан вә итагатьтән гафил булып, уен-көлке белән мәшгуль булган һәм каберне вә үзенең череп юкка чыгуын онытткан бәндә – иң хәсрәтле бәндә. Бозыклык таратып чиктән чыгып киткән һәм үзенең тамчыдан халикъ кылынып балчыкка әйләнәсен онытткан бәндә – иң хәсрәтле бәндә. Динне дөнья малы, урын вә байлык җыяр өчен кулланган бәндә – иң хәсрәтле бәндә. Динне шөбһәләр белән бозган бәндә – иң хәсрәтле бәндә. Комсызлыгы гөнаһка сөйрәгән бәндә – иң хәсрәтле бәндә. Әгъвасы[117] адаштырган бәндә – иң хәсрәтле бәндә. Дөнья эстәүе вә аңа омтылуы белән түбәнсетелгән бәндә – иң хәсрәтле бәндә».***

Зүһдтә[118] әд-Даххәктән риваять ителә: «Пәйгамбәребез ﷺ янына бер кеше килде дә: «Әй Аллаһның илчесе! Кешеләр арасыннан иң зөһедлесе[119] кем?», – дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Иң зөһедле кеше — кем каберне вә череп юкка чыгуын онытмый, дөньяның зиннәтен ташлый, фәни дөньяга караганда мәңгелек ахирәтне эсти, иртәгәсен үзенең көне дип уйламый[120], һәм үзен кабер әһелләреннән исәпли»,*** – диде».

---

117 Коткы, нәфескә хуҗа була алмау

118 Ибен Әбү әд-Дүнья

119 Дөньяга омтылмау, ашкынмау. Кайберәүләр: «Дөнья рәхәтлеген ташлап, ахирәт рәхәтлегенә омтылу», – диделәр

120 Исән булырмын дип уйламый